ГЛАВА ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12 июль, 2024 ел Алабуга шәһәре № 20

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, гавами тыңлаулар уздыру юлы белән «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирлегендә яшәүчеләрнең Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү турында» 2024 елның 11 июлендәге 359 номерлы карарында күрсәтелгән инициативаны карау буенча гавами тыңлауларны 2024 елның 9 августына билгеләргә.

2. Гавами тыңлаулар үткәрү урыны итеп Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре, Нефтяниклар проспекты, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан Алабуга муниципаль районы Советы бинасының зур залын билгеләргә, гавами тыңлаулар үткәрү вакыты - 13. 00 сәгатьтә.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә, 2024 елның 17 июленә кадәр гавами тыңлаулар үткәрү турында хәбәр итәргә һәм проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында (http://городелабуга.рф) урнаштырырга.

2024 елның 14 августына кадәр Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында (http://городелабуга.рф) һәм массакүләм мәгълүмат чаралары матбугат басмаларында гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә, гавами тыңлаулар үткәрү комиссиясе составын расларга.

5. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

5.1. гавами тыңлауларны оештыручы - гавами тыңлаулар уздыру комиссиясе;

5.2. проектның электрон версиясе һәм аңа мәгълүмати материаллар Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының рәсми сайтында, «Алабуга муниципаль районы» бүлегендә урнаштырыла.

6. Гавами тыңлаулар үткәрү комиссияләренә:

6.1. әлеге карар белән билгеләнгән сроклар нигезендә гавами тыңлаулар әзерләүне тәэмин итәргә;


6.2. гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне әзерләргә һәм рәсмиләштерергә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Район Башлыгы Р.М. Нуриев

Алабуга муниципаль районы Башлыгының
2024 елның 12 июлендәге ____
номерлы карарына 1 нче кушымта




Условные обозначения

- граница Республики Татарстан
- граница Елабужского муниципального района
- граница Большешурнякского сельского поселения
- административный центр поселения
- населенные пункты
- территории, исключаемые из состава Елабужского муниципального района и Большешурнякского сельского поселения

Алабуга муниципаль районы Башлыгының
2024 елның 12 июлендәге ____
номерлы карарына 3 нче кушымта

Проект буенча тәкъдимнәрен исәпкә алу

1. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составына керүче «Олы Шүрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең чикләрен, «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен Удмурт Республикасы чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чикләренә туры китерү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр, 1 нче кушымта нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә түбәндәге адрес буенча юллана: Алабуга шәһәре, Мира проспекты, 12 нче йорт, 214 нче кабинет яисә 4-56-04 телефоны аша язмача рәвештә гавами тыңлаулар тамгасы белән кертелә.

2. «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составына керүче «Олы Шүрнәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең чикләрен, «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге чикләрен Удмурт Республикасы чиге белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чикләренә туры китерү мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр: эш көннәрендә 2024 елның 9 августына кадәр 8-00 сәгатьтән 17-00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Алабуга шәһәре, Мира проспекты, 12 нче йорт, 214 нче номерлы кабинетка яисә почта аша («Гавами тыңлаулары» конвертында тамга белән) яки 4-56-04 телефоны аша язмача рәвештә гавами тыңлаулар тамгасы белән кертелә.

4. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге тарафыннан теркәлә.

Алабуга муниципаль районы
Башлыгының
2024 елның 12 июлендәге ____
номерлы карарына 3 нче кушымта

Гавами тыңлаулар үткәрү комиссияләре
СОСТАВЫ

| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Функцияләр | Вазифасы |
|---|---|---|
| Р.Л. Исланов | гавами тыңлаулар үткәрү | Алабуга муниципаль районы Башлыгы урынбасары, комиссия рәисе |
| Р.Х. Шәйхелисламов | гавами тыңлауларны әзерләү, эксперт | Алабуга муниципаль районы шәһәр төзелеше буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, рәис урынбасары |
| К.Ф. Гыйзззәтуллина | беркетмәне алып бару | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы урынбасары, секретаре. |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| Г.А. Миннекаева | депутатларга хәбәр итү | Алабуга район Советының оештыру бүлеге башлыгы; |
| Э.Р. Әхмәдиева | гомуми сораулар | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| А.А. Томилин | ТКХ, челтәр, транспорт | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Г.С. Билалова | Җир, категория, милекчеләр | Алабуга муниципаль районының Җир-мөлкәт палатасы МКУ рәисе |
| Н.Д. Курамшин | социаль блок (медицина, мәдәният, мәгариф) | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| А.В. Косов | авыл хуҗалыгы | Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы |
| Р.Ф. Гыйлаҗиев | урман хуҗалыгы | «Алабуга урманчылыгы» ДКУ җитәкче-урманчысы; |
| Килешү буенча | халыкка хәбәр итү | Алабуга шәһәре территориаль иҗтимагый үзидарә Советы җитәкчеләре |